**Республика Татарстан**
**Глава Верхне-Чершилинского сельского поселения Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.11. 2021г № 5

2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Усай авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1. Усай авылындагы ФАП бинасы янында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 19 ноябренә 09.00 сәгатькә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Югары Чыршылы авыл җирлегенең Усай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан , Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Усай авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2) Усай авылында Сабантуй, өлкәннәр көне үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

3) МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

4) Усай авылында артезиан скважиналары территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары, буяу сатып алу, эшләр өчен түләү);

5) Усай авылы урамнарын яктырту өчен светодиод лампалар сатып алу һәм урнаштыру;

6) “Сарман” район газетасында некролог бастыру.

«ӘЙЕ «ЮК»

3.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http:// sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Камалетдинов